ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«12» июля 2018 ел **№ 603**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында»2016 елның 22 апрелендәге 476 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы халкының пассажирлар йөртүгә һәм транспорт хезмәтенә булган ихтыяҗын канәгатьләндерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 26.12.2015 ел, № 220-ФЗ, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында "Федераль законны гамәлгә ашыру турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 18 июнендәге 107-ТРЗ номерлы карары, "Җайга салынулы тарифлар буенча муниципаль маршрутларда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 18 июнендәге карары нигезендә яңа шәһәр яны автобус маршрутлары булдыру зарурилыгы сәбәпле, Арча район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында» Арча

муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 апрелендәге 476 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрына үзгәрешләр кертергә һәм аны яңа редакциядә, кушымта нигезендә, 5 яңа шәһәр яны автобус маршрутын урнаштыруны исәпкә алып, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.Ә. Галимуллин